ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАТАР СУКСУЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ЖИТӘКЧЕСЕ

423736, Татар Суксуы авылы,
Гагарин ур., 1б нчы йорт.
Тел.5-24-45

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
РУКОВОДИТЕЛЬ ТАТАРСКО-СУКСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
423733, село Татарские Суксы,
ул. Гагарина,дом 1б, Тел. 5-24-45

КАРАР
07.06.2019

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№14

## 2019 елгы су коену сезоны чорында Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Татар Суксуы авыл җирлеге ачык сулыкларда коенуны тыю турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының “Татар Суксуы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 03.06.2019 ел, №ПР-125 санлы карары белән, Татар Суксуы авыл җирлеге территориясендә пляжлар һәм суда массакүләм ял итү урыннары булмау сәбәпле, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Татар Суксуы авыл җирлеге Башкарма комитеты, гражданнарның гомерен һәм сәламәтлеген саклау максатларында

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елгы су коену сезоны чорында Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Татар Суксуы авыл җирлеге ачык сулыкларда коенуны тыярга.
2. Су коену сезоны дәвамында җирлек территориясендә ачык сулыкларда коенуны тыю турында халык белән аңлату эшләре һәм балаларны махсус контрольдә тоту кирәклеге турында белешмәләкләр өләшеп аңлату эшләре алып барырга;
3. Балаларны карауучысыз тоту һәм өлкән кешеләр тарафыннан контрольдә тоту рөхсәт ителгән гаиләләрне аерым контрольгә алырга, мондый гаиләләр белән шәхси профилактик эш алып барырга, ата-аналарга кул куйдырып коенуны тыю турында белешмәлекләр тапшырырга;
4. Ачык сулыкларда су коенуны тыю турында аншлаглар урнаштырырга;
5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында “Татар Суксуы авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга.
6. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Татар Суксуы авыл җирлеге
башкарма комитеты
җитәкчесе вазифасын
башкаручы Г.Г.Хамматуллина